КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2019 ел, 13 ноябрь | г.Казань | № 1036

837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм коммерциягә карамаган оешмаларның 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 13 ноябрь, 1036 нчы
карары белән расланды

837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба – оешмалар) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән бирүдән тыш) (алга таба – субсидияләр) механизмын билгели.

2. Субсидияләр оешмаларга 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында бирелә.

3. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче, субсидия бирүне гамәлгә ашыручы булып Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

4. Субсидияләр оешмаларга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Субсидияләр субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килүче айның 1енә түбәндәге таләпләргә туры килүче оешмаларга бирелә:

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәсе булмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокукый актлар нигезендә акча алмаган;

үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмаган, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган булырга тиеш;

бирелгән бюджет акчасын максатчан һәм (яки) нәтиҗәле файдаланмауга юл куймаган.

6. Субсидия алуга конкурс нигезендә оешмаларны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр була:

837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүне гамәлгә ашыруга лицензиясе булу;

үз милкендә яки башка законнар нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә кулланыла торган Зил-131, КАМАЗ-4310 (4350, 5350 һәм аларның модификацияләре), Урал-4320 (4320-31, 43206 һәм аларның модификацияләре) маркалы укыту армия автомобильләре булу.

7. Субсидия алуга конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен оешмалар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирүгә заявка (алга таба – заявка);

гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга кертелгән барлык үзгәрешләр турындагы документларның билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләрен;

837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүне гамәлгә ашыруга мөмкинлек бирә торган һөнәри укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия күчермәсен;

салым органының килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килүче айның 1е хәленә карата Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәсе булмавынраслый торган белешмә кәгазен;

килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килүче айның 1енә субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмавын раслый торган документларны;

оешманың килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килүче айның 1енә бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә акча алмавын раслый торган документларны;

үз милкендә яки башка законнар нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә кулланыла торган Зил-131, КАМАЗ-4310 (4350, 5350 һәм аларның модификацияләре), Урал-4320 (4320-31, 43206 һәм аларның модификацияләре) маркалы укыту армия автомобильләре булуын раслый торган документларны;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен чыгымнарның оешма җитәкчесе тарафыннан расланган, финанс-икътисадый нигезләве теркәлгән сметасын;

оешманың килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килүче айның 1енә үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмаган, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган булуы турындагы оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган гарантия хатын;

оешманың 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүне гамәлгә ашыруын раслый торган лицензия;

кредит оешмасында ачылган, субсидия күчерелә торган исәп-хисап счеты турында мәгълүмат.

Оешма тарафыннан бу пунктның дүртенче – җиденче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә соратып ала.

8. Оешмаларның конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга заявкаларын кабул итә башлау һәм кабул итеп бетерү һәм теркәүгә алу вакытлары, заявкаларны карап тикшерү графигы Министрлык боерыгы белән раслана. Әлеге мәгълүмат заявкаларны кабул итә башлаган көнгә кадәр эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

9. Министрлык оешмаларның заявкаларын, аларга теркәлгән документлар белән бергә, тапшырылган көннән бер эш көне эчендә кабул итә һәм теркәүгә ала.

10. Субсидия алуга конкурс нигезендә оешмаларны сайлап алу конкурс комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның составы һәм эш тәртибе Министрлык боерыгы белән раслана.

11. Конкурс комиссиясе заявкаларны кабул итү һәм теркәүгә алу вакыты тәмамланганнан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә аларны карап тикшерә һәм конкурс нигезендә сайлап алуның җиңүчесе турында карар кабул итә.

Конкурс нигезендә сайлап алу оешманың бу Тәртипнең 6 нчы пунктында билгеләнгән критерийларга туры килүен бәяләүне үз эченә ала. Критерийларга туры килүен һәм аларның дөреслеген раслый торган документларның булуы өчен һәр документка 5 балл бирелә. Балларның максималь саны 10 балл тәшкил итә.

Конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча максималь балл җыйган оешма конкурс нигезендә сайлап алуның җиңүчесе дип таныла.

Конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча конкурс комиссиясе беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә торган конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары турында карар чыгара.

Конкурс комиссиясе карары нигезендә Министрлык эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында боерык рәвешендәге карарны кабул итә.

12. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

оешма бу Тәртипнең 5 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

оешма тарафыннан тапшырылган документлар бу Тәртипнең 7 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү яки әлеге документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

оешма тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

13. Кабул ителгән карарның нәтиҗәләре турындагы хәбәрнамә оешмага тиешле карар кабул ителгән көннән бер көн эчендә Министрлык тарафыннан язма рәвештә җибәрелә.

14. Субсидия бирү Министрлык белән субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән оешма (алга таба – субсидия алучы) арасында төзелгән килешү нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча гамәлгә ашырыла.

Килешү субсидия бирү турындагы карар билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә төзелә.

15. Субсидия, килешү төзелгәннән көннән 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча, субсидия алучының Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына күчерелә.

16. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү шартлары һәм тәртибе;

субсидияне күчерү вакытлары;

бу Тәртипнең 17 нче, 21 нче, 22 нче пунктлары нигезендә субсидиядән файдалану турында, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисаплылык бирү вакытлары, формасы һәм тәртибе;

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия алучының Татарстан Республикасы бюджетыннан аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру хокукы;

субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия өлешен агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары;

финанс хисап елында файдаланылмый калган субсидия өлеше финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт (Министрлык аларны файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә);

субсидия алучының һәм субсидияләр бирү турындагы килешү йөкләмәләрен үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булган затларның Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанас министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

алынган субсидияләр исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны (югары технологияле чит ил җиһазын, чималын һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) тыю;

бу Тәртип белән билгеләнгән шартларны бозган очракта, килешүне өзү тәртибе;

субсидия алучының максатчан файдаланылуын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

субсидия алучының бу Тәртип шартларын һәм төзелә торган килешүне үтәве турындагы нигезләмә.

17. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча бер елга кимендә 300 кеше әзерләү.

18. Субсидиянең күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$С_{фо} = К_{п} \times Р,$$

монда:

$С_{фо}$ – 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия күләме;

$К_{п}$ – 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча әзерлек үтүче гражданнарның план буенча саны;

Р – 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча бер гражданны әзерләү өчен 36 455 сумга тигез булган кыйммәте.

19. Субсидия акчасы түбәндәгеләр белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә җибәрелә:

белгечләр әзерләүгә бәйле персоналның, шул исәптән укытучыларның, җитештерүгә өйрәтү мастерларының, һөнәри дәрәҗәдә машина йөртергә өйрәтү мастерларының (инструкторларның) хезмәте өчен түләү;

командировка чыгымнары;

физик һәм юридик затларның хезмәт күрсәтүләре, шул исәптән элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәтне карап тоту хезмәтләре һәм аларга бәйле башка хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә салымнар өчен түләү;

837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүне оештыру һәм үткәрү өчен төп чаралар һәм матди запаслар сатып алу, шул исәптән ягулык-майлау материалларына чыгымнар.

20. Субсидияләр алучылар субсидияләр керү һәм аларны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

21. Субсидияләр алучылар субсидияләр бирелгән елдан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр Министрлыкка субсидияләрдән файдалану һәм субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бирә.

22. Субсидияләрдән файдалану турындагы һәм субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисап бу Тәртипкә теркәлгән кушымтадагы форма буенча бирелә.

23. Субсидияләр алучылар хисапны субсидияләрдән файдалануны раслый торган документлар нигезендә төзи.

24. Хисап тегелгән, нумерланган һәм субсидия алучының җитәкчесе, баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган һәм мөһер белән (булганда) расланган булырга тиеш.

25. Хисапка карата кисәтүләр булмаган очракта, Министрлыкның министр урынбасарлары арасыннан җаваплы хезмәткәре хисапка виза сала һәм мөрәҗәгать итүчегә эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә хисап кабул итү турында хәбәр итә.

26. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидияләр алучыларның субсидия алу шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен законнар нигезендә тикшерә.

27. Субсидияләр Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы субсидияләр биргәндә билгеләнгән, Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартларны бозганда;

субсидия алучы аны алу өчен дөрес булмаган (тулы булмаган) мәгълүматлар һәм документлар тапшырганда;

субсидияләрдән файдалану һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турындагы хисапны килешү белән билгеләнгән вакытта тапшырмаганда;

субсидияләр акчасын максатчан файдаланмаганда;

субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешмәгәндә.

28. Килешү белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр өлеше субсидия алучы тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

29. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 27 нче һәм 28 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытлары бозылган очракта, Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны законнар белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

30. Субсидияләрдән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
кушымта

Форма

Субсидияләрдән файдалану һәм субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисап

1 нче таблица

| Т/с | Субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү | Гражданнар саны | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | план-йөкләмә нигезендә 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге буенча укырга тиешле | 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге буенча әзерлек үтү өчен җибәрелгән | 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге буенча әзерлек үтү барышында укудан чыгарылган | коммерциягә карамаган оешмада укыган, әмма Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясендә имтихан тапшыра алмаган | 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге буенча фактта әзерлек үткән |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Белем алучылар саны, кеше | | | | | |

2 нче таблица

| Т/с | Чыгымнар исеме | Чыгымнар, сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге буенча әзерлек үтү барышында укудан чыгарылган белем алучылар өчен чыгымнар | коммерциягә карамаган оешмада укыган, әмма Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясендә имтихан тапшыра алмаган белем алучылар өчен чыгымнар | 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге буенча фактта әзерлек үткән белгечләр өчен чыгымнар | 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге буенча әзерлек үтү өчен җибәрелгән белем алучылар өчен чыгымнар | субсидия буенча кире кайтарылырга тиешле чыгымнар | искәрмәләр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүне оештыру һәм үткәрү өчен төп чаралар һәм матди запаслар сатып алу чыгымнары | | | | | | |
| 1.1. | Белгечләр әзерләү өлешендә ягулык-майлау материаллары өчен чыгымнар, шул исәптән: | | | | | | |
| | автомобиль бензины | | | | | | |
| | автомобиль газы | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | дизель ягулыгы | | | | | | |
| | май һәм майлау әйберләре | | | | | | |
| 2. | 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле персоналның хезмәте өчен түләү чыгымнары, шул исәптән: | | | | | | |
| | укытучылар | | | | | | |
| | җитештерүгә өйрәтү мастерлары | | | | | | |
| | машина йөртергә өйрәтү мастерлары (инструкторлар) | | | | | | |
| | Хезмәт өчен түләүгә исәпләүләр – 30,2 процент (20,2 процент) | | | | | | |
| | Өстәмә түләүләр белән хезмәт өчен түләү – барлыгы | | | | | | |
| 3. | Командировка чыгымнары | | | | | | |
| 4. | Физик һәм юридик затларның хезмәт күрсәтүләре өчен түләү чыгымнары, шул исәптән: | | | | | | |
| | элемтә хезмәтләре | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | транспорт хезмәтләре | | | | | | |
| | коммуналь хезмәтләр | | | | | | |
| | мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр | | | | | | |
| | башка хезмәтләр | | | | | | |
| 5. | Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә салымнар өчен түләү чыгымнары | | | | | | |
| 6. | Барлыгы | | | | | | |

Җитәкче ___________/__________________
(имзасы) (инициаллары, фамилиясе)

М.У.

Баш бухгалтер ___________/__________________
(имзасы) (инициаллары, фамилиясе)

20 __ ел, « ___ » ___________________